Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

18.10.2022 ел

Менделеевск ш.

№643

Генераль планнан яисә җирдә файдалану
һәм җирлекне төзү кагыйдәләреннән өземтә бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 декабрендәге 836 номерлы карары белән расланган Генераль планнан яисә җирдән файдалану һәм җирлекне төзү кагыйдәләреннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   "Формалаштырылган гарызнамәне формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер электрон форма гарызнамәсен тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон формадагы гарызнамә ачыкланганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән гарызнамәнең электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга» http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасарына йөкләргә

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.В.Метальников